12+
Яңа, 2017 ел белән!
DARELFONUN
УНИВЕРСИТЕТ
Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы
**23** декабрь, **2016** ел
№ 8 (153)




# Лаеклы җиңү!

«Darelfønyn» газетасы корреспонденты, Татарстан радиосының «Яшьлек аланы» тапшыруының алып баручысы, татар журналистикасы кафедрасы магистранты Раил Садретдинов, КФУның «Ел студенты – 2016» бәйгесендә җиңү яулап, иң яхшы журналист дип табылды. Без аның белән горурланабыз! Чын күңелдән котлыйбыз!

## ИНТЕЛЛЕКТУАЛЬ УЕН

2015 нче елдан башлап, КФУда Spell Battle интеллектуаль уены оештырылып килә. Быел аның юбилей уены булды. Катнашучылар арасында студентлар гына түгел, ә мәктәп укучылары да бар. Юбилей уенында алда үткәрелгән сезоннарның ярымфиналистлары, финалистлары һәм җиңүчеләре көч сынашты. 10нчы Юбилей уенының абсолют җиңүчесе булып **Гыйздәтова Эльза** танылды!

## ИҖАТЧЫЛАР КӨЧ СЫНАШТЫ

Шушы көннәрдә КФУның Лев Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында иҗат белән шөгыльләнә торган студентлар һәм мәктәп укучыларына йөз тотып оештырыла торган «Шигъри Сабантуй» һәм «Илһамлы каләм» бәйгеләре булып узды. Бәйгедә барлыгы 372 катнашучы көч сынашты.

## КФУның ЯҢА ЖУРНАЛЫ

2016 нчы елның 15 нче декабрендә КФУда инглиз телендә чыга торган KAZAN UNIVERSITY LAW REVIEW дип аталган өр-яңа журнал дөнья күрде. Басманың төп максаты – чит илләрдән килгән кунакларны хәзерге Россия хокук фәне белән якыннанрак таныштыру. Журналның беренче санында профессор **Илдар Тархановның** язмасы һәм профессор **Михаил Челышевның** вафатына кадәр язылган, әмма бүген дә актуаль булып калган язмалары урын алды.



## Кадерле дуслар!

2017 елны каршы алырга санаулы көннәр калып бара. Матур традиция буенча, бу вакытта үтеп баручы елга нәтиҗә ясала һәм яңа елга планнар корыла.

2016 ел Казан федераль университеты тормышында матур нәтиҗәләргә, кызыклы вакыйгаларга бай булды. Университет төп күрсәткечләр буенча Россия Федерациясе югары уку йортлары арасында 4 нче урынга күтәрелде, дөньякүләм танылу алган «THE» рейтингына һәм «Лингвистика» юнәлеше буенча иң алдынгы 200 югары уку йорты исемлегенә керде. Шулай ук бездә төрле өлкәләргә караган җитди мәсьәләләрне тикшерүгә багышланган күпсанлы халыкара форумнар, симпозиумнар, конференцияләр һәм очрашулар үтте. Казан федераль университетының Россиядә генә түгел, ә бөтен дөньяга танылуы уку йортында студентлар санын тагын да арттырды. Бездә укучы чит ил студентлары гына да 4100 дән артып китте.

Бер ел эчендә берничә лаборатория һәм дистәләгән «OpenLabs» үз эшен башлап җибәрде, байтак яңа башлангычка нигез салынды. КФУ традицияләрен дәвам итеп, ректор бакчасында танылган патриот-шагыйрь Муса Җәлилгә һәйкәл ачылу да киң җәмәгатьчелек тарафыннан хуплап каршы алынды. Олы хезмәтегез өчен зур рәхмәт сезгә, кадерле дуслар!

Яңа елга без зур планнар белән керәбез. Укытучы-профессорларның фәнни егәре, иҗади теләк, зур омтылыш һәм бердәмлек алда торган бурычларны үтәп чыгуда таяныч булып тора. Бу юлда тагын да зуррак уңышларга ирешербез, яңа үрләр яуларбыз дип ышанам.

Хөрмәтле хезмәттәшләр, студентлар, аспирантлар, магистрлар һәм хезмәткәрләр! Сезгә һәм якыннарыгызга ныклы сәламәтлек, иҗат уңышлары, шатлык-куанычлар телим. Яңа елда барлык теләкхыялларыгыз тормышка ашсын. Якынлашып килүче Яңа ел котлы булсын!

**Илшат Гафуров,**
КФУ ректоры

# «ГУМАНИТАРИЙ» ҺӘМ «ТЕХНАРЬ»ЛАР БЕРЛӘШӘ

**2017 ЕЛ КФУда ЖУРНАЛИСТИКА БЕЛЕМЕ ЕЛЫ ҺӘМ МАТЕМАТИК ЛОБАЧЕВСКИЙ ЕЛЫ БУЛЫП ТАРИХКА КЕРЕП КАЛАЧАК.**

**Илгиз ШӘКҮРОВ**

### ХӘТЕРНЕ ЖУРНАЛИСТЛАР ЯШӘТӘ

2017 нче елда университетта журналистика белгечлеге ачылуга 55 ел тула. Мәгълүм булганча, университетта журналистика бүлеге 1962 нче елда тарих-филология факультетында оештырыла. Юбилейны лаеклы билгеләп үтү өчен, оештыру комитеты булдырылды. Университетның ректораты, медиаүзәк вәкилләре, Журналистика һәм медиакоммуникацияләр югары мәктәбе кафедралары мөдирләреннән торган бу комитетны ректор **Илшат Гафуров** үзе җитәкли.

«*Журналистика белеме елының бөек математик Лобачевский елы белән туры килүенә без бик сөендек. Чөнки әлеге бөек математик университет тарихыннан аерылгысыз. Бүгенге көндә гаммәви мәгълүмат чараларының кешелек тормышында тоткан урынын без аңлап бетермибез әле. Мәсәлән, шул ук Лобачевский турындагы хәтерне бары тик журналистлар гына яшәтә ала. Гаммәви мәгълүмат чаралары кешеләргә ул хәтерне җиткермәсә, искә төшереп тормаса, ул юкка чыгар иде*», – ди КФУның Журналистика һәм медиакоммуникация югары мәктәбе директоры **Леонид Толчинский**. Югары мәктәп бинасында җәен ремонт үткәрелгән, махсуслашкан яңа аудиторияләр барлыкка килгән, практика узу өчен ньюсрум эшләнгән. Шулай ук ток-шоулар уздыра торган заманча җиһазлы телевизион студия сафка баскан.

Татар журналистикасы кафедрасы мөдире, профессор **Васил Гарифуллин** да әлеге яңалыкны бик шатланып кабул иткән. «*Әлбәттә, бу вакыйга бәйрәм белән генә чикләнеп калырга тиеш түгел. Без университетның журналистика бүлегенә, шул исәптән милли журналист кадрларын әзерләүгә дә игътибар артыр, дип ышанабыз*», – ди ул. Аның фикеренчә, математика, физика һәм химия белән генә чикләнергә ярамый. Әйе, әлеге фәннәр кысаларында университетны халыкара дәрәҗәгә күтәрерлек ачышлар һәрдаим ясалып тора. Тик көн саен диярлек информацион сугышлар булып торган заманда журналистларның роле зур һәм кешеләр тарафыннан аңлауга лаек булырга тиеш.



Рәсем дизайны: Алинә Галиәхмәтова

### УЛ ХӘТТА РЕКТОР БУЛГАН!

Бөек математик Николай Лобачевский үз тормышын университетыбыз белән студент елларыннан ук бәйли. Ул аны тәмамлап кына калмаган, ә 1827-1845 нче елларда Казан император университеты ректоры да булган! Яңа елда Н.Лобачевскийның тууына 225 ел була. Шуңа күрә киләсе елның аның исемен йөртүе дә очраклы түгел.

Ректор Илшат Гафуров белдергәнчә, Лобачевскийга багышланган елның программасы Казан университетына гына түгел, ә республиканың барлык уку йортларына, шулай ук башка федераль университетларга да кагылачак. «*Лобачевский исеме илнең барлык математик җәмгыятьләренә дә билгеле. Бу елны нәтиҗәле итүдә математиклар гына түгел, ә тарихчылар да тырышырга тиеш*», – диде ул.

КФУдагы Лобачевский исемендәге математика һәм механика институтының студентлар активы рәисе **Татьяна Курылева** 2017 нче ел университет тарихында аеруча якты булып истә калачак, дип уйлый. «*Мин бөек математик исемен йөрткән институтта укуым белән горурланам. Николай Иванович исемен без бик хөрмәт итәбез, яңа елда исә бу хөрмәт тагын да артсын иде. Студентлар активы рәисе буларак, шуны әйтә алам: активистлар галимнең туган көнен билгеләп үтүгә бик теләп әзерләнәләр. Моның өчен университетта бөтен мөмкинлекләр бар. Уңышлар безгә!*» – ди ул.

Менә шулай КФУ төрле яклап камилләшә һәм студентларына яңа мөмкинлекләр ачып кына тора. 2017 нче елга планлаштырылган барлык эшләр уңышлы булсын, дигән теләктә калабыз. Яңа, 2017 ел әнә шулай «гуманитарий»лар өчен дә, «технарь»лар өчен дә юбилейлар елы булып тарихка керергә җыена.

КФУНЫҢ ЖУРНАЛИСТИКА ҺӘМ МЕДИАКОММУНИКАЦИЯ ЮГАРЫ МӘКТӘБЕ ОСТАХАНӘСЕНӘ КУНАК БУЛЫП БЕЛЬГИЯ ТАТАРЛАРЫНЫҢ БЕРЛЕГЕ РӘИСЕ ЛИЛИЯ ВӘЛИЕВА КИЛДЕ.

# «АУРУПАДА ТАТАРСТАННЫ КАЙГЫРТЫП ЯШИМ!»

**Алсу ГАЗТДИНОВА**



Лилия ханым, университетны тәмамлагач, Мәскәүдә журналист булып эшләвен, соңыннан, «Сельская жизнь» гәҗитенең үз хәбәрчесе булып, Бельгиягә китүен сөйләде, үз мисалында телләр белүнең эшендә, тормышында зур ярдәм булуын ассызыклап узды. Лилия ханым, тормыш иптәше киңәше белән фламанд телен өйрәнүе аркасында, Россия журналисты буларак кына түгел, ә Бельгия журналистлары белән беррәттән, бертигез шартларда эшләргә мөмкинлек тууын әйтеп китте. Шунда ук студентларга стажировкалар үтү мөмкинлекләрен дә җиткерде: берәр басмага, радиога рәхәтләнеп стажировкага языларга була, әмма хезмәт хакы түләнми икән. Аның каравы, студентларга шушы эштән иминият килешүе ясала, транспорт һәм төшке аш өчен акча бирелә. Стажировкага килгәндә, тел белү дәрәҗәсен тикшермиләр, «Кеше стажировкага килә икән, димәк, телне белә» дигән фикердә торалар.

Аурупада журналистларның ирекләре зуррак икәнен Л.Вәлиева болай дип аңлатты: «Журналистика, коммерция нигезендә эшләү сәбәпле, дәүләттән аерылган».

Л.Вәлиеваны еш кына радиога чыгыш ясарга чакыралар, күптән түгел Лёвен шәһәрендә урнашкан Католик университетында (безнең университетның тугандашы) чыгыш ясаган. *«Бар җирдә дә, Россия турында бераз сөйләп, сүзне Татарстан Республикасы ягына борам, Аурупада Татарстанны кайгыртып яшим»*, — дип елмая Лилия ханым.

Бельгиядәге көндәлек тормыш хакында да сораулар булды: мәчетләр, Татар берлегенең җыелу урыны бармы, эмигрантларга караш ничек, Татар берлегендә ничә татар кешесе санала һ.б. Һәр сорауга Лилия Вәлиева бәйнә-бәйнә җавап бирде. Бельгия татарлары берлегендә 500 татар булуын, ел саен татарлар саны артуын, быел ноябрь аенда яңа туган өч сабыйга исем куштыруны ул ләззәтләнеп сөйләде. Мәгълүмат чаралары аша Татарлар берлеге белән элемтәгә нотариус керүен аерым тарих итеп сөйләп алды Лилия ханым. Нотариус үзендә мәрхүм бер татар хатынының васыятнамәсе барлыгын белдерә. Ул хатын — Гүзәл Мөхетдинова-Амальрик — гомере буена рәссам була, ире — тарихчы, әдәбиятчы, философ Андрей Амальрик белән заманында СССРдан куылып, гомерләрен чит илләрдә үткәрәләр. Ире алданрак үлә, Гүзәл Мөхетдинова үзе 2014 елда вафат була, ясалган рәсемнәр җыелмасын Россиягә алып кайтуларын теләми, чөнки илдән куылуына бик рәнҗегән була ул. Нотариус рәсемнәр җыелмасын Бельгиянең татарлар берлеге кабул итмәс микән, дигән сорау белән мөрәҗәгать итә. Рәсемнәр җыелмасын 2017 елның 21 гыйнваренда махсус күргәзмәдә күрсәтәчәкләр.

Җирле халыкның татарларны хөрмәт итүләрен, Бельгиядәге милләттәшләребезнең андагы башка халыкларны да татар мәдәнияте белән мөмкин кадәр күбрәк таныштырырга омтылуларын, җәй көннәрендә татар балалары өчен туган телгә өйрәтү мәктәпләре оештыруларын Л.Вәлиева горурланып тасвирлады. Ил күләмендәге мөһим вакыйгалар, Татарстан Республикасына һәм милләтебезгә кагылышлы чаралар, аларны оештыру нечкәлекләре хакында кунак аудиториягә тәфсилләп сөйләде, сөйләгән саен, тыңлаучыларның кызыксынуы арта гына барды.

*«Бар җирдә дә Россия турында бераз сөйләп, сүзне Казан, Татарстан Республикасы ягына борам, Аурупада Татарстанны кайгыртып яшим»*



# КФУ – ЯҢА МӨМКИНЛЕКЛӘР МӘЙДАНЫ

**Айгөл АБДРАХМАНОВА**

КАЗАН (ИДЕЛ БУЕ) ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТЫ СТУДЕНТЛАР ӨЧЕН БӨТЕН ШАРТЛАРНЫ БУЛДЫРА. ШУЛ ИСӘПТӘН ТӨРЛЕДӘН-ТӨРЛЕ СТИПЕНДИЯЛӘР АЛУ МӨМКИНЛЕГЕ ДӘ БИРӘ.

«Стипендияне каты кысып тотарга ярамый, буылып үлә», «Студент халкы – ач халык» ише мәзәк гыйбарәләр еш очрый. Ай азагы җитте исә, студентларның телләрендә шул тылсымлы сүз – стипендия. Ә бер атнадан кабат шул тылсымны көтү башлана. Гомер-гомергә шулай булган инде ул, дияр кайберәүләр. Ә менә мин моның белән һич кенә дә килешмим. Тырыш, яхшы укучы, актив, сәләтле студентларның (ялкаулыгын җиңә алган һәркем шушы исемлеккә эләгә ала) стипендияләре югары белемле, квалификацияле белгечләрнекеннән дә күбрәк. Чын әгәр!

Бүгенге көндә КФУның бюджет стипендия фондына, гадәти стипендиядән тыш, яхшы укучылар өчен югары стипендия, социаль ярдәмгә мохтаҗлар өчен махсус стипендия, төрле өлкәдәге уңышлар өчен бер тапкыр бирелә торган социаль стипендия керә. Моннан тыш бюджетка карамаган махсус стипендияләр дә бар. Студент, магистр һәм аспирантлар өчен КФУда Оксфорд Россия фонды, «BP Exploration Operation Company Limited», «ИОО Фонд Содействия», «Р-Фарм», «Диаэм» шәхси стипендияләре, «Ел студенты» ТР студентлар премиясе, «Прайсвотерхаус Куперс Раша Б.В.», «VOIGES: Аурора Берлегенең Идел буе халыкара тикшерену үзәге» һәм «КФУның 10 иң яхшы инновацион идеясе» премияләре каралган.

Моннан тыш КФУ студентлары һәм аспирантларына чит илләрдә белем алу өчен махсус грант-стипендияләр бар. Татарстанда гына калырга һәм республика үсешенә үз өлешен кертергә теләүчеләр өчен ТР Фәннәр Академиясенең махсус стипендиясе булдырылган. Физика институты магистрантлары **Ләйсән Абдразакова** һәм **Дарья Шуртакова** (*фотода*) радиофизика өлкәсендәге фәнни хезмәтләре өчен, ТР Фәннәр Академиясе стипендиатлары булдылар.

*Югары стипендия акча чыганагы түгел. Стипендия ул – алга барырга, фән белән шөгыльләнергә стимул*

Соңгы ярты ел нәтиҗәләре буенча, КФУның 19 студенты һәм аспиранты Татарстан Республикасының махсус дәүләт академия стипендиясе лауреаты, сентябрь аенда Фундаменталь медицина һәм биология институты аспиранты **Татьяна Ширшкова** РФ хөкүмәтенең аспирантлар өчен махсус стипендиясе иясе булды. КФУның 10 студенты Альфа-шанс стипендиясе, 13 студент һәм 9 аспирант РФ хөкүмәте стипендиясе, 8 студент һәм 4 аспирант Россия Президенты стипендиясе лауреаты исемен алдылар.

**РФ Хөкүмәте һәм РФ Президенты стипендиатлары**

**752** конкурстант

**21** КФУ студенты

**13** КФУ аспиранты

**КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫ СТУДЕНТЛАРЫ ЯУЛАГАН ҮРЛӘР МОНЫҢ БЕЛӘН ГЕНӘ ЧИКЛӘНМИ. МӘСӘЛӘН, 22 НЧЕ ДЕКАБРЬ КӨННЕ КФУның ИҢ АЛДЫНГЫ СТУДЕНТЛАРЫ ҺӘМ АСПИРАНТЛАРЫ КАЗАН ШӘҺӘРЕ МЭРЫНЫҢ ШӘХСИ СТИПЕНДИЯСЕ БЕЛӘН БҮЛӘКЛӘНДЕ. СТИПЕНДИЯ ӨЧЕН КӨРӘШ ШАРТЛАРЫ, ФӘННИ ЭШЛӘР, ПРОЕКТЛАР БӘЙГЕСЕ КӨЗ КӨНЕ ИГЪЛАН ИТЕЛГӘН ИДЕ. 4 НЧЕ НОЯБРЬГӘ КАДӘР БӘЙГЕГӘ БЕРНИЧӘ ЙӨЗ ЭШ КАБУЛ ИТЕЛГӘН. ШУЛАРНЫҢ 51е ИКЕ СЕКЦИЯ БУЕНЧА СОҢГЫ ТУРГА УЗГАН: СОЦИАЛЬ-ГУМАНИТАР, ТЕХНИК ҺӘМ ТАБИГЫЙ ФӘННӘР БУЕНЧА. НӘТИҖӘДӘ 39 АВТОР ШӘҺӘР МЭРЫ СТИПЕНДИАТЫ БУЛДЫ. ҖИҢҮЧЕЛӘР АРАСЫНДА КФУ СТУДЕНТЛАРЫ БУЛУЫ АЕРУЧА КҮҢЕЛЛЕ.**

# БЕЗНЕКЕЛӘР, ТАНЫШ БУЛЫГЫЗ!

**ФАРСЫЕВА ГҮЗӘЛ, Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтындагы Татаристика һәм тюркология югары мәктәбенең 1 нче курс магистранты:**

Бәйгегә тәкъдим ителгән эшем бертуган Гриммнарның татар теленә тәрҗемә ителгән «Rotkappchen» әкиятенең лингвистик үзенчәлекләрен өйрәнүгә багышланган. Әлеге фәнни хезмәтне икенче курс студенты чагында ук эшли башлаган идем. Башта тәрҗемә мәсьәләсенең билгеле бер юнәлешен генә алып өйрәндем. Соңрак ул киңәйде, үсте, тирәнтен өйрәнелде. Чыгарылыш квалификация эшен дә шушы темага якладым. Фәнни эшемне башкарганда, авырлыклар да булды. Иң беренче чиратта, кайбер тәрҗемә әсәрләрендә тәрҗемәчеләрнең исемнәре күрсәтелми. Эзләнергә кирәк. Арадашчы тел белән эш иткәндә, авторның кайсы тәрҗемәчегә таянганын ачыклау шулай ук зур игътибар һәм эзләнү таләп итә. Тәрҗемәләргә нинди бәя бирү өчен, тәрҗемәчеләрнең башка хезмәтләре белән дә танышырга кирәк. Аңа хас үзенчәлекләрне ассызыклау, характерын билгеләү өчен, һәрдаим эзләнү алып бару, күп уку зарур. Бу фәнни эшнең практик әһәмияте дә юк түгел. Гадәттә, телләрне өйрәнгәндә, бер класска кергән телләрне чагыштырып өйрәнәләр. Ә без башкарган фәнни эш нигезендә, агглютинатив һәм флектив телләрне үзара чагыштырып, чит телләрне өйрәнү мөмкинлеге барлыкка килә.

Хәзерге көндә институтыбызда республика күләмендә телләрне саклап калу, үстерү өчен зур көч куела. Без — бай әдәби мираслы, үз тарихыбыз белән дан тоткан халык. Туган телеңне белү, ярату, аралаша алу — зур бәхет. Татар теле — бай, зәвыклы, моңлы тел. Миңа калса, татар телен чагыштырма планда өйрәнү аның кыйммәтен арттыра гына. Чөнки шул ук инглиз, алман телләреннән туган телебез берни белән дә ким түгел. Шушы бүлектә укып, фәнни эзләнүләремне тел юнәлешендә алып бару минем өчен бик әһәмиятле. Бәлки, гомуми планда бу кечкенә генә бер күрсәткечтер, әмма зирәк



халкыбыз юкка гына «тамчыдан күл җыела» дип язмаган.

Үз хезмәтләреннән тәм табып эшләүче биргән белемне дөньяның бернинди хәзинәләре дә алыштыра алмый. Әлеге уңышым белән мин фәнни җитәкчем, Лев Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының Г.Тукай исемендәге Татаристика һәм тюркология югары мәктәбе җитәкчесе, профессор, филология фәннәре докторы **Йосыпова Әлфия Шәүкәт** кызына бурычлы. Ул куйган максат, аның төпле киңәшләреннән башка фән юнәлешендә үсү, камилләшү бик авыр булыр иде. Гаҗәеп остазлар булганда, яңа үрләр үзләре үк тез чүгә төсле.

**ГАНИЕВА АЙСЫЛУ,**
**Психология һәм белем бирү институтының II курс магистранты:**

Фәнни хезмәтем профессиональ спортчыларны әзерләүче тренерлар эшчәнлеге белән бәйле. Бәхәс чыгу ихтималы булганда, тренерларның үз-үзләрен тотышы һәм үз-үзен саклау механизмын фәнни җитәкчем белән бергәләп өйрәндек.

Идеаль тренер-остаз сау-сәламәт, физик әзерлекле, рухи һәм психологик яктан нык булырга тиеш. Тик, кызганычка каршы, күпчелек спортчылар (бигрәк тә балалар һәм яшүсмер спортчылар) яхшы остаз белән эшләү мөмкинлегеннән мәхрүм. Чөнки Казанда һәм Татарстанда яхшы әзерлекле спортчыларны уеннарга әзерли ала торган тренерлар саны бик аз. Шуңа күрә без, барлык әһәмиятле таләпләрне истә тотып, тренер вазифасына кандидатлар сайлап алу методикасын булдырдык.

Без тренерларның антиципацион халәтен (алдан күрә һәм фаразлый алу сәләтен), конфликтологик белемен, борчуларга тотрыклылыгын тикшердек. Танылган психологлар В.Д.Менделевич, Р.Плутчик, К.Томас алымнарына нигезләнеп, төрле тестлар оештырдык. Нәтиҗәдә, тренер вазифасына алына торган кешенең киңкырлы, төрле өлкәдә белемле булырга тиешлеге ачыкланды.

Хәзер фәнни хезмәтебезне гамәлгә куюягын кайгыртабыз. Санкт-Петербург дәүләт университеты доценты, спорт психологиясе буенча халыкара абруйга ия белгеч **Владимир Константин улы Сафонов** мине үз төркемenә чакырды.



# ЭКОЛОГ-ГЕОГРАФТАН ЖУРНАЛИСТИКАГА БЕР АДЫМ

**Айгөл АБДРАХМАНОВА**

НИЧЕК УЙЛЫЙСЫЗ, ИДЕАЛЬ ЖУРНАЛИСТ НИНДИ БУЛЫРГА ТИЕШ? БЕЛЕМЛЕ, ТЫРЫШ, ОПЕРАТИВ?! Ә ИҢ ЯХШЫ ЖУРНАЛИСТ ИСЕМЕН АЛЫР ӨЧЕН НИШЛӘРГӘ КИРӘК? БУ СОРАУГА ҖАВАПНЫ «ШӘХЕС» РУБРИКАСЫНЫҢ КУНАГЫ - БЕЗНЕҢ КОЛЛЕГА, РАИЛ САДРЕТДИНОВ БЕЛӘ.



Фото герой архивыннан

*«Моңарчы журналист һөнәрен сайлаганга үкенмәдем, алга таба да үкенергә язмасын»*

**– Раил, журналистикага ничек килеп кердең?**

– Дөресен генә әйткәндә, балачакта кем генә булырга хыялланмадым. Мәктәптә кем булырга телисең дигән иншалар сырлаганда, космонавт дип яза идем, соңрак артист буласым килде. Аннан укытучы, табиб, географ-эколог та булырга уйладым. Әмма журналист булырмын дип, һич кенә дә башыма китерми идем. Безнең мәктәптә атна буе дежур торган сыйныф шул ук вакытта стена газетасы да чыгара иде. Бу эшкә катнашып киттем. 8 нче сыйныфта укыганда, үзебезнең Балык Бистәсе районының «Авыл офыклары» газетасында беренче язмам чыкты. Газетада үз исемеңне күрү – бик зур шатлык бит ул бала вакытта. Татар теле һәм әдәбияты укытучыбыз да, язу сәләтемне күреп, һәрчак илһамландырып торды, үзе дә темалар тәкъдим итә иде. Мин шулай мәктәбебезнең һәм авылыбызның актив хәбәрчесе булып киттем. Мәктәпне тәмамлап чыкканчы, я эколог-географ, я журналист булам дип әзерләндем.

**– Яраткан фәннәрең нинди иде?**

– Мәктәптә география иде. Район олимпиадаларында, төрле фәнни-тикшеренү конференцияләрендә катнашып, җиңү дә яулый идем. Хәтта КФУга документларымны да берьюлы Экология институтына һәм журналистика бүлегенә тапшырдым. Экология институтына үтүчеләр исемлегендә дә бар идем. Әмма күңел журфакны үз итте. Фән белән кызыксынган кеше булларак, география буенча төрле эзләнү-тикшеренү конференцияләрендә катнашуым, география укытучым биргән дәресләр, киңәшләр миңа бүген дә бик булыша.

**– Һәр журналистның үз алдына куйган даһи миссиясе була. Синең миссияң нинди?**

– Бүгенге катлаулы, бөтен мәгълүмат чаралары аша күбрәк күңелсез хәбәрләр таратылган заманда, кешеләргә тормышыбызда яхшылыкка да урын бар бит дигән фикерне җиткерү. Мин моны һәр язмам, радиода яңгыраган һәр таптшыруым саен әйтергә омтылам.

**– Сереңне чиш әле: КФУның иң яхшы журналисты булу өчен нишләргә кирәк?**

– Тырышырга! Минем бүгенге җиңүем – ул 5 еллык эш нәтиҗәм. Мондый бәйгеләрдә катнашудан курыкмаска киңәш итәр идем. Биредә син башкаларның эшен күрәсең, үзеңнеке белән чагыштырып карыйсың, үз алдыңа яңа максатлар билгелисең. Иң мөһиме – «Мин җиңүче» дип, туктап калмаска, алга таба да камилләшергә кирәк. Әлеге җиңүем өчен мин КФУның татар журналистикасы кафедрасының һәр укытучысына, үзебезнең «Дарелфөнүн» газетасы коллективына бик рәхмәтле.

**– Журналистика белән бәйле иң әрсез хыялың нинди?**

– Әлбәттә, бу чынга ашмаслык хыял түгел: чит илдә журналист буларак стажировка үтәргә хыялланам.

**– Раил, ә кеше буларак син нинди?**

– Мин – тыныч кеше. Иң якын «дусларым» – өстәл лампасы, куен дәфтәре, каләм һәм ноутбук. Шау-шулы компанияләрне хупламыйм. Башлаган эшемне ахырына кадәр җиткерергә тырышам. Дөрес, бер төрле генә эш эшләп озак утырырга да яратмыйм. Минем белән танышып, дуслашырга теләгән кеше шушыларны белсә, бик яхшы.

**– Күп кызларны кызыксындыра торган сорау: КФУның иң яхшы журналистының йөрәгенә хуҗа булган берәр кыз бармы?**

– Әлегә юк. ВКдагы статуслардагыча: актив эзләнүдә.

БЕЗГӘ КУНАККА КАЗАН (ИДЕЛ БУЕ) ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТЫНЫҢ ТАТАР ЖУРНАЛИСТИКАСЫ КАФЕДРАСЫ ДОЦЕНТЫ, ФИЛОЛОГИЯ ФӘННӘРЕ КАНДИДАТЫ, «DARELFӨNYN» ГАЗЕТАСЫНЫҢ БАШ МӨХӘРРИРЕ САБИРОВА ЛӘЙЛӘ РӘШИТ КЫЗЫ ҺӘМ «DARELFӨNYN» ГАЗЕТАСЫ ХӘБӘРЧЕЛӘРЕ АБДРАХМАНОВА АЙГӨЛ БЕЛӘН САДРЕТДИНОВ РАИЛ КИЛДЕЛӘР.

# ҺӨНӘР САЙЛАУ – ҖИТДИ ЭШ

**Энҗе ӘХМӘТҖАНОВА,** Казан шәһәре Совет районы 111нче рус-татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең 8 нче «А» сыйныфы укучысы



Без алар белән һөнәрләр турында сөйләштек. Сүзебез күбрәк журналист һөнәре турында барды. **Ләйлә апа** белән **Айгөл апа** журналист кешедә нинди сыйфатлар булырга тиешлеге турында сөйләделәр. Журналист кеше өчен иң мөһим сыйфатлар ул — максатчанлык, игътибарлы булу, анализлый белү, тырышлык, кызыксынучанлык, аралашучанлык, кешеләрнең хәленә керә белү һ.б. икәнен белдек. Журналист булу өчен, КФУга укырга керергә кирәклеген аңладык.

Кунакларыбызның ничек журналист булып китүләре турында да сорадык. **Раил абый Садретдинов**, мәсәлән, мәктәптә укыганда, география фәне белән бик кызыксынган, олимпиадаларда катнашкан. Шул юл буенча китәргә дә уйлаган. Әмма ул, мәктәпне бетергәндә, инде үзенең журналист булырга теләгәнен аңлаган. География фәнен яхшы белүе аңа хәзер дә нык ярдәм итә. Чөнки ул күп җирләрдә була, төрле кешеләр белән аралаша. Бүгенге көндә ул әле «Татарстан» радиосында «Яшьлек аланы» тапшыруы алып баручысы да. Алып баручы серләренә ныграк төшенү өчен, ул безне радиога кунакка да чакырды. Без бик теләп риза булдык. Якын арада безне сыйныф җитәкчебез Розалия Хадиулловна радиога алып барырга сүз бирде.

Очрашу вакытында без шулай ук «Darelfөnyn» газетасы турында да сөйләштек. Әлеге газета Казан (Идел буе) федераль университетының беренче татарча студентлар газетасы икәнен белдек. Биредә уку йортына бәйле чаралар, анда белем алган, танылган шәхесләр, алдынгы студентлар, гомумән, студентлар тормышы турында мәгълүматлар алырга була икән. Айгөл апа Абдрахманова, әлеге газетаның корреспонденты буларак, язган кызыклы мәкаләләребезне үзенә җибәрергә кушты. Безгә оялмаска, шигырьләр, мәкаләләр язып, үз сәләтләребезне сынап карарга киңәш итте.

Әлеге очрашуда без үзебезне кызыксындырган күп сорауларга җаваплар алдык. Күңелебездә булган икеләнүләр югалды. Нәкъ менә журналист булырга теләүчеләребезнең үзенә ышанычы артты дип уйлыйм. Кем белә, бәлки безнең арадан да бервакыт кунакларыбыз шикелле танылган журналистлар үсеп чыгар, һәм без дә яшь иҗатчыларга үрнәк булырбыз. Әлегә һөнәрләр белән танышуыбыз дәвам итә. Һөнәр бит ул кием генә түгел. Аны сайлауга бик җитди карарга, үзеңнең күңелеңә ошаган һөнәрне сайлаганда, һич кенә дә ялгышмаска кирәк.

# КФУ РАДИКАЛИЗМГА КАРШЫ КӨРӘШӘ

**Айгөл САЛИХОВА**

17-18 НЧЕ ДЕКАБРЬ КӨННӘРЕНДӘ КАЗАН ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТЫНДА «МУЛЬТИМӘДӘНИ ДӨНЬЯДА ИСЛАМ» ДИП АТАЛГАН VI ХАЛЫКАРА ФОРУМ ЭШЛӘДЕ.

Форумда Россиядән һәм 4 чит илдән ислам буенча 150 белгеч, мөселман эшлеклеләре, дини мәгариф өлкәсе һәм дәүләт-конфессиональ сәясәтенең күренекле вәкилләре чыгыш ясады. Быелгы форумның төп темасы «Конфессияара килешү һәм радикализмны җиңү» булды.

Форум үз эшен «Ислам в современном мире» журналының Казандагы вәкиллеген ачуга багышланган килешүне имзалау белән тәмамлады.



• Фотода: Дамир хәзрәт Мөхетдинов, РФ мөселманнары Диния нәзарәте рәисенең беренче урынбасары

• **Student's blog**

# Соңга калып килсәң-күчтәнәч!

**Алсу ЗИНУРОВА,** Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты

СТУДЕНТ ТОРМЫШЫНДА НИНДИ ГЕНӘ КЫЗЫК ХӘЛЛӘР БУЛМЫЙ. БЕР ЯКТАН – КӨЛКЕ, ИКЕНЧЕ ЯКТАН ҮЗ-ҮЗЕҢНЕ КАЯ КУЯРГА БЕЛМИ ТОРГАН ХӘЛДӘ КАЛДЫК.

Без магистратурада укыйбыз. Дәрес вакытлары бик уңайлы, сәгать биштән соң гына башлана, димәк, көндез эшләргә мөмкинлек бар. Икенче яктан — уңайсыз, чөнки эштән соң туры укырга килгәч, ашарга өлгереп булмый. Бер парны укыйбыз да төркемебезнең яртысы диярлек ашарга йөгерә. Ике дәрес арасында 10 минут тәнәфес. Якында гына урнашкан кафега төшеп тамак ялгап алганчы, ун минут кына түгел, 20 минуты да узгалый кайчак. Шулай, гел бер парга соңга калабыз да инде без. Җитмәсә, ул вакыт аралыгында кафеда студентларга ташлама да бар. Алдагы дәресне үзебезнең яраткан мөгаллимебез алып бара, хәлебезгә керер дип, гел бер үк көнне, бер үк вакытта парга соңга калып керәбез. Ә менә бу мин сөйлисе соңга калуыбыз ахыргысы булды бугай.



Гадәттәгечә, староста мөгаллимгә: «Исәнмесез, Фәлән Фәлән, сез бүген киләсезме?» — дип хат язды. Телефон булгач, шәп инде. Шулай аралашып кына торабыз. «Әйе!» – дип җавап килде укытучыдан. Бу юлы төркемдәшләр аркылы түгел, үзем кисәтеп куйыйм дип, старостабыз: «Фәлән Фәлән, безнең бит ашыйсы килә!» — дип читләтеп әйтергә булды. Инде без тынычлап ашарга китәргә җыенганда, безнең мөгаллимебез: «Нәрсә алып килим соң?» – дип язып җибәрмәсенме… Староста да, югалып калмыйча, диалогны дәвам итте: «Менюда нәрсәләр бар?» — дип сорады.

Шуның белән шаяру онытылды, ашыга-ашыга тамак ялгыйбыз, телефонны карарга да онытылган. Ә бит Фәлән Фәләннән хат килгән: «Менюда ата пәри башы белән, ана пәри түше бар», — диелгән. Мондый сүзләрдән соң күңелгә бераз шик тә керде. Мөгаллимебез, соңга калсак та, дәрескә керергә рөхсәт итте. Бар да әйбәт дип, дәфтәр, каләмнәребезне чыгарып, дәрескә әзерләндек. Шулчак мөгаллимебез: «Кайсыгызның бик каты ашыйсы килде?» – дип сорап куймасынмы. Дәшми торасы инде, тик староста паузаны бүлеп: «Минем», — диде. Мин дә дөресен әйттем инде. Яныбызга килде дә яраткан мөгаллимебез өстәлебезгә йогурт, кабартма һәм шоколад чыгарып салды. Башкаларны белмим, ә мин җир ярылып китсә, шунда төшәрдәй булдым. Ни еларга, ни көләргә белмичә утырганда: «Сезгә биш минут бирәм, тамак ялгап алыгыз», — дип, чыгып та китте. Габдулла Тукайның «Су анасы» әкиятендәге карак малайның «…Шуннан бирле мин дә әйберләргә тими башладым», — дигән юллары искә төште. Шуннан бирле без дә дәресләргә соңга калмый башладык.

• **Сораштыру**

# Кыш бабайга хат …

СИЗӘСЕЗМЕ, ЯҢА ЕЛГА САНАУЛЫ КӨННӘР ГЕНӘ КАЛДЫ. БАЛАЧАКТА ИНДЕ КҮБЕБЕЗНЕҢ БУ ВАКЫТТА КЫШ БАБАЙГА ХАТЛАРЫ ЯЗЫЛГАН БУЛА ИДЕ. Ә СТУДЕНТЛАР АРАСЫНДА ӘЛЕГЕ ТРАДИЦИЯ ДӘВАМ ИТӘ МИКӘН?

**ЛӘЙЛӘ ӘХМӘДИЕВА, Лобачевский исемендәге Математика һәм механика институты студенты:** Кыш бабайга киләсе елда дәүләт имтиханнарын яхшы билгеләргә биреп, әйбәт кенә диплом яклап чыгарга, исән-сау укуны тәмамларга теләвемне белдереп, хат яздым.

**АЛИНӘ ЗИННУРОВА, А.М. Бутлеров исемендәге Химия институты студенты:** Укытучыларга юмартлык, студентларга автомат имтиханнар, озын каникуллар, һәркемгә сәламәтлек һәм яңа яуган ак кардай бәхет сорадым.



**ЭЛЬЗА ГЫЙЗДӘТОВА, Л.Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты студенты:** Дөньядагы барлык кешеләрнең дә күңелләре матур, үзләре бәхетле, акыллы, бер-берләренә карата мәрхәмәтле булуларын сорап хат язган идем.

***P.S.:*** *Без дә үз чиратыбызда әлеге теләкләрнең чынга ашуын һәм Яңа елның бәхетле мизгелләргә бай булуын теләп калабыз!*

***Яңа ел белән!***

12+
DARELFONUN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Мөхәррир в.б. - Л.Р.Сабирова
Иҗат коллективы: Р.Р.Садретдинов, А.А.Абдрахманова
Корректор - Р.Ә.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – ФГАОУ ВО Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 334 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru
Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2016 елның 08 сентябрендә ПИ № ТУ 16-01506 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00, 22.12.2016. «Фолиант» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Профсоюзная, 17в.